**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменения в параметры осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения

В целях совершенствования правового регулирования отношений в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов **постановляю**:

1. Внести изменение в раздел III параметров осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения, утвержденных Указом Президента Республики Татарстан от 12 апреля 2013 года № УП-303 «Об определении параметров осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 14 декабря 2013 года № УП-1216, от 12 июня 2014 года № УП-572, от 23 апреля 2015 года № УП-412, от 16 июля 2015 года № УП-654, от 15 августа 2015 года № УП-724, от 10 февраля 2016 года № УП-131, от 9 июля 2016 года № УП-588, от 7 июля 2017 года № УП-608, от 19 мая 2018 года № УП-381, от 30 мая 2018 года № УП-397, от 26 июля 2018 года № УП-541 и от 19 февраля 2019 года № УП-130), изложив пункты 6–10 в следующей редакции:

«6. Запрещается любительская и спортивная охота во всех государственных природных зоологических (охотничьих) заказниках регионального значения на период до 2023 года.

7. Запрещается любительская и спортивная охота на глухаря в период летне-осенне-зимнего сезона охоты 2019 года и весеннего сезона охоты 2020 года во всех охотничьих угодьях, за исключением охотничьего хозяйства «Беркут».

8. Запрещается любительская и спортивная охота на тетерева в период летне-осенне-зимнего сезона охоты 2019 года и весеннего сезона охоты 2020 года во всех охотничьих угодьях.

9. Запрещается любительская и спортивная охота на серую куропатку в период летне-осенне-зимнего сезона охоты 2019 года в охотничьих хозяйствах: «7 завода», «Аксубаевское», «Актанышское», «Алькеевское», «Арское», «Атнинское», «Багряжское», «Бакчасарайское», «Балтасинское»,

«Беркут», «Волжское», «Волжско-Камское», «Вятское», «Глухарь», «Егерь», «Елабужское», «Заинское», «Зюзеевское», «Камский берег», «Камское раздолье», «Камско-Икское», «Карамалинское», «Кзыл-Юлское», «Красноборское», «Куйбышевское», «Лебяжье» (Мензелинский и Черемшанский районы), «Лубянское», «Менделеевское», «Мензелинское», «Новомензелинское», «Охотник», «Охотничьи традиции», «Охотничьи традиции 2», «Радуга», «Рыбно-Слободское», «Сармановское», «Свиногорье», «Северное», «Трофей», «Тюрнясевское», «Учебно-опытный Сабинский лесхоз», «Урахчинское», «Урнякское», «Уруссинское», «Усинское», «Челнинское», «Черемшанское», «Шуманское», «Южное», «Янтыковское», а также в общедоступных охотничьих угодьях Агрызского, Аксубаевского, Арского, Высокогорского, Елабужского, Заинского, Нурлатского, Рыбно-Слободского, Сармановского, Спасского, Тукаевского, Черемшанского районов.

10. Запрещается любительская и спортивная охота на зайца-русака в сезон охоты 2019/2020 года в охотничьих хозяйствах: «Ак Барс», «Албаевское», «Алькеевское», «Атнинское», «Бакчасарайское», «Балтасинское», «Бугульминское», «Волжское», «Вятский берег», «Вятское», «Глухарь», «Дубрава», «Егерь», «Елабужское», «Забава», «Камский берег», «Красноборское», «Краснооктябрьское», «Кукморское», «Лубянское», «Менделеевское», «Муслюмовское», «Нурма», «Омара», «Пестречинское», «Поповское», «Рыбно-Слободское», «Свиногорье», «Северное», «Берсут», «Трофей», «Урахчинское», «Урман», «Уруссинское», «Усинское», «Учебно-опытный Сабинский лесхоз», «Шуманское», «Южное», «Юкя», а также в общедоступных охотничьих угодьях Агрызского, Бавлинского, Бугульминского, Высокогорского, Елабужского, Зеленодольского, Кайбицкого, Лаишевского, Мамадышского, Муслюмовского, Рыбно-Слободского, Тукаевского, Чистопольского районов.».

2. Настоящий Указ вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

**Президент Республики Татарстан** — **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
24 мая 2019 года
№ УП-294

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларына үзгәрешләр кертү турында**

Аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» 2013 елның 12 апрелендәге ПУ-303 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1216 номерлы, 2014 елның 12 июнендәге ПУ-572 номерлы, 2015 елның 23 апрелендәге ПУ-412 номерлы, 2015 елның 16 июлендәге ПУ-654 номерлы, 2015 елның 15 августындагы ПУ-724 номерлы, 2016 елның 10 февралендәге ПУ-131 номерлы, 2016 елның 9 июлендәге ПУ-588 номерлы, 2017 елның 7 июлендәге ПУ-608 номерлы, 2018 елның 19 маендагы ПУ-381 номерлы, 2018 елның 30 маендагы ПУ-397 номерлы, 2018 елның 26 июлендәге ПУ-541 номерлы һәм 2019 елның 19 февралендәге ПУ-130 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, аулау параметрларының III кисәгенә, 6–10 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«6. 2023 елга кадәрге чорга төбәк әһәмиятендәге барлык дәүләт табигать зоология (аучылык) заказникларында һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.

7. 2019 елның җәйге-көзге-кышкы ау сезонына һәм 2020 елның язгы ау сезонына «Беркут» аучылык хуҗалыгыннан тыш, барлык аучылык биләмәләрендә суерга һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.

8. 2019 елның җәйге-көзге-кышкы ау сезонына һәм 2020 елның язгы ау сезонына барлык аучылык биләмәләрендә көртлеккә һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.

9. 2019 елның җәйге-көзге-кышкы ау сезонына «7 завод», «Аксубай», «Актаныш», «Әлки», «Арча», «Әтнә», «Багражь», «Бакчасарай», «Балтач»,

«Беркут», «Идел», «Идел-Кама», «Вятское», «Глухарь», «Егерь», «Алабуга», «Зәй», «Зүзәй», «Камский берег», «Камское раздолье», «Кама-Ык», «Карамалы», «Кызыл Юл», «Красный Бор», «Куйбышев», «Лебяжье» (Минзәлә һәм Чирмешән районнары), «Лубян», «Менделеевск», «Минзәлә», «Яңа Минзәлә», «Охотник», «Охотничьи традиции», «Охотничьи традиции 2», «Радуга», «Балык Бистәсе», «Сарман», «Свиногорье», «Төньяк», «Трофей», «Төрнәс», «Укыту-тәҗрибә Саба урман хуҗалыгы», «Уракчы», «Үрнәк», «Урыссу», «Усы», «Чаллы», «Чирмешән», «Шуман», «Көньяк», «Янтык» аучылык хуҗалыкларында һәм Әгерҗе, Аксубай, Арча, Биектау, Алабуга, Зәй, Нурлат, Балык Бистәсе, Сарман, Спас, Тукай, Чирмешән районнары ачык аучылык биләмәләрендә соры кыр тавыгына һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.

10. 2019/2020 еллар ау сезонында «Ак Барс», «Албай», «Әлки», «Әтнә», «Бакчасарай», «Балтач», «Бөгелмә», «Идел», «Вятский берег», «Вятское», «Глухарь», «Дубрава», «Егерь», «Алабуга», «Забава», «Камский берег», «Красный бор», «Кызыл Октябрь», «Кукмара», «Лубян», «Менделеевск», «Мөслим», «Нурма», «Омара», «Питрәч», «Поповское», «Балык Бистәсе», «Свиногорье», «Төньяк», «Берсут», «Трофей», «Уракчы», «Урман», «Урыссу», «Усы», «Укыту-тәҗрибә Саба урман хуҗалыгы», «Шуман», «Көньяк», «Юкә» аучылык хуҗалыкларында һәм Әгерҗе, Баулы, Бөгелмә, Биектау, Алабуга, Зеленодольск, Кайбыч, Лаеш, Мамадыш, Мөслим, Балык Бистәсе, Тукай, Чистай районнары ачык аучылык биләмәләрендә соры куянга һәвәскәрләр авы һәм спорт авы тыела.».

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көннән 10 көн узгач үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2019 ел, 24 май
№ ПУ-294